КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 март г.Казань № 179

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссияләрен төзү турында» 2018 ел, 21 апрель, 271 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссияләрен төзү турында» 2018 ел, 21 апрель, 271 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 2 октябрь, 892 нче; 2019 ел, 13 июль, 573 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 19 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 20 март, 209 нчы; 2020 ел, 2 июнь, 460 нчы; 2020 ел, 12 ноябрь, 1014 нче; 2021 ел, 20 май, 346 нчы; 2022 ел, 24 гыйнвар, 41 нче; 2022 ел, 9 август, 783 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1285 нче; 2023 ел, 22 февраль, 174 нче; 2023 ел, 12 апрель, 450 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре территорияләрендә үсеше алдан билгеләнә торган социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре территорияләрендә үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе турындагы нигезләмәнең 2 пунктында «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре территория-

ләрендә үсеше алдан билгеләнә торган социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре территорияләрендә үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Яр Чаллы» үсеше алдан билгеләнә торган территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Динар Рәфикъ улы Шакировны кертергә;

әлеге карар белән расланган «Түбән Кама» үсеше алдан билгеләнә торган территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Динар Рәфикъ улы Шакировны кертергә;

әлеге карар белән расланган «Чистай» үсеше алдан билгеләнә торган территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Динар Рәфикъ улы Шакировны кертергә;

әлеге карар белән расланган «Зеленодольск» үсеше алдан билгеләнә торган территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (инвестиция үсеше буенча), комиссия секретаре Резида Ислам кызы Габидуллинаны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Динар Рәфикъ улы Шакировны;

Зөлфәт Флүн улы Хәбибуллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

әлеге карар белән расланган «Менделеевск» үсеше алдан билгеләнә торган территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Динар Рәфикъ улы Шакировны кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин